**«Чәчәк нигә боекты?» хикәясе.** Кызчыкның әнисенә ярдәм итүе, табигатьне яратуы.

**Борис Вайнерның «Искиткеч китап».** Елның дүрт фасылы. Аларның һәрберсе үзенчә матур булуы.

**IX. Эш беткәч көләргә ярый.**

**Ләбиб Леронның «Пирамида» хикәясе.** Укучыларда белем алуга теләк тудыру. Укымыйча гына белемле булып булмавын ачыклау.

*Теоретик төшенчә. Юмор.*

**Алмаз Гыймадиев.**

**«Зөлфия + ... мин» хикәясе.** Яшүсмерләрне беренче мәхәббәт хисләренең сурәтләнеше. Язуда гына түгел, тормышта да хаталар җибәрергә ярамавын ачыклау.

**Шәүкәт Галиев.**

**«Ул кем?» «Әлләкем», «Мәрзия мәсьәләсе» шигырьләре.** Шагыйрьнең табышмак, юмористик шигырьләрендә бала хисләренең ачылышы.

**Ятлау өчен тәкъдим ителә торган әсәрләр**

Дәрдемәнд, "Кил, өйрән...".
Ф.Кәрим, "Сөйләр сүзләр бик күп алар...".
Р.Фәйзуллин, "Табигать кочагында".

**Дәрестән тыш (өстәмә) уку өчен тәкъдим ителгән әсәрләр**

(укытучы сайлавы буенча)

Башмак (татар халык әкияте).
Төлке белән Алёнушка (рус халык әкияте).
Карга ни өчен исемен әйтеп бетерми? (башкорт халык әкияте).

Куркак юлдаш (татар халык әкияте).
Каюм Насыйри. Күләгә.
Фәнис Яруллин. Хәтерсез күке.
Владимир Даль. Кар кызы.
Ганс Христиан Андерсен. Борчак өстендәге принцесса.
Рудольф Эрих Распе. Сигез аяклы куян.
Тукай-Апуш. Рабит Батулладан.
Илдус. Ибраһим Газидан.
Мөнирә Булатова.
Фатих Кәрим. Ватаным өчен.
Мәңгелек хәтер. Лев Кассильдан.
Сугышчан бурыч. Фаил Шәфигуллиннан.
Оҗмах балалары. Мәдинә Маликовадан.
Көнбагыш чәчәге. Фоат Садриевтан.
Әхмәт Рәшитов. Кояшлы ил — бәхет иле.
Мәгъсүм Хуҗиннан. Туган көн.
Нури Арсланов. Ринат авылда.
Габделхәй Сабитов. Чәчәк нигә боекты?
Борис Вайнер. Искиткеч китап.
Шәүкәт Галиев. Мәрзия мәсьәләсе.

**6нчы сыйныф**

**6 нчы сыйныф укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:**

– әдәби әсәрләрне, сүзләрен дөрес әйтеп, йөгерек уку;
– авторның әйтергә теләгән фикерен аңлау, үз мөнәсәбәтен белдерү, өлешләргә бүлә һәм планын төзи белү;
– әдәби − теоретик төшенчәләрне рус әдәбият белеме белән тәңгәлләштерү;
– татар әдәбиятының дөнья культурасында тоткан урынын аңлау;
– авторларның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача күзаллау;
– 6 нчы сыйныф өчен минимумга кергән әсәрләрнең кыскача эчтәлеген, төп геройларын, күтәрелгән проблеманы белү;
– 10 −12 татар, рус, чит ил язучысы, шагыйрьләре исемнәрен һәм алар язган әсәрләрне белү;
– 3 − 4 сәнгать әһеленең тормышы, иҗаты турында мәгълүматлы булу;
– Казан һәм Татарстан төбәгендәге мәдәният учаклары (музей, театр, концерт залы, һ. б.), балалар матбугаты турында белү;
– төрле халыкларның фольклор үрнәкләрен татар халык авыз иҗаты белән чагыштыру;
– төрле халыкларның киң таралган мифларыннан хәбәрдар булу, берничә мисал китерә белү;
– 5 мәкаль, 5 әйтемне русча эквивалентлары белән истә калдыру;
– мәкаль белән әйтем, миф белән әкият, халык җыры белән автор җыры арасындагы аерманы белү;
– төрле авторларның 2 − 3 шигырен яттан сөйли белү;
– сүзлекләр, энциклопедияләр, Интернет-ресурслардан файдаланып, үзенә кирәкле материалны табу;
– төрле темаларга проект эше яклау;
– әдәби әсәрне тормыш белән бәйләп, үз гамәлләренә бәя бирү.

**Курс темаларының эчтәлеге**

**Өйрәнелергә тиешле әсәрләр минимумы**

1. Г.Тукай, «Шүрәле» әкият-поэмасы, «Туган авыл» шигыре;

2. М.Гафури, «Ана» шигыре;
3. Һ.Такташ, «Мокамай» поэмасы;
4. М.Җәлил, «Чәчәкләр» шигыре;
5. Ә.Еники, «Туган туфрак» хикәясе;
6. Г.Бәширов, «Туган җирем — яшел бишек» повестеннан «Язгы сабан туйлары» өзеге.

**Искәрмә:** минимумнан тыш өстәмә уку материалын сайлау мөмкинлеге, укытучы карамагында кала. Биредә мәктәпнең уку планында һәм еллык календарь графигында исәпкә алынаган сәгатьләр истә тотыла.

**I. Мифлардан чынбарлыкка.**
**Халык авыз иҗаты.**
Фольклор – халыкның коллектив иҗат җимеше. Анда халыкның теләк-омтылышының чагылышы. Фольклорның вариантлы булуы. Фольклор әсәрләренең жанрларын гомуми күзаллау. Балалар фольклоры (бишек җырлары, табышмаклар, тизәйткечләр, мәкальләр һ.б.). Башка халык авыз иҗаты белән чагыштыру.
*Әдәбият теориясе. Фольклор. Халык авыз иҗаты.*
**Мифлар. Татар халык мифлары.**
Мифлар – кешеләрнең дөньяны фантастик аңлавы. Мифик геройлар турында төшенчә. Миф белән әкиятнең аермасы. Рус, грек мифлары белән чагыштыру. «Шүрәле», «Шүрәлене ничек алдарга?» «Су иясе», «Өй иясе», «Дедал белән Икар» мифлары. Мифларны өйрәнгән галимнәр. Язучылар иҗатында мифик геройлар. Рабит Батулланың “Албасты” пьесасы.
*Әдәбият теориясе.Миф.Мифик геройлар.*
**Мәкальләр һәм әйтемнәр.**
Мәкальнең акыл бирү, сөйләмне матурлау өчен кулланылуы. Мәкальләрнең тематикасы. Әйтемнең күчерелмә мәгънәдә кулланылган, сөйләмнең эмоциональ көчен арттыра торган жанр булуы. Мәкаль белән әйтемнең аермасы. Татар мәкальләре һәм әйтемнәренең русча эквивалентлары.
*Әдәбият теориясе. Мәкаль, әйтем.*
**II. Халык моңнары: җырлата да, елата да...**
**Халык җырлары.**
Халык җырларының авторы халык булуы. Аларның вариантлылыгы. Халык җырларының жанрлары. Йола җырлары, аларның килеп чыгу үзенчәлеге. Йола бәйрәмнәреннән Сөмбелә бәйрәме. Чуваш халык бәйрәме Чуклеме. Тарихи җырлар. **“Көзге ачы җилләрдә”** җыры. Уен җырлары. **“Кәрия-Зәкәрия”** җыры.
*Әдәбият теориясе. Халык җырлары. Халык җыры жанрлары. Йолалар, йола җырлары. Тарихи җырлар. Уен җырлары.*
**Шигърияттә халык көе.**
Шагыйрьләрнең кайбер шигырьләре халык тарафыннан көйгә салынуы. Г.Тукайның “Туган тел” шигыре. Аның төрле телләргә тәрҗемә ителүе.
**Г.Тукайның “Туган авыл”** шигыре. Аның дә халык җыры кебек яратып җырлануы, киң таралган булуы. Композитор А.Монасыйпов турында кыскача белешмә. Кешенең балачагы үткән туган якның кадере.
*Әдәбият теориясе. Автор җырлары.*
**Татарстан Республикасы гимны.**
Гимнның дәүләт символы булуы. Гимн уйнала торган очраклар. Гимнны тыңлау тәртибе. Татарстан Республикасының Дәүләт гимны авторлары Р.Байтимеров, Р.Яхин. Гимн текстының эчтәлеге, көе.
*Әдәбият теориясе. Гимн.*
**Җырны башкаручы – җырчы**.

Жырның яшәвендә башкаручының роле. Җырчы Р. Ваһапов – милли профессиональ эстрадага нигез салучы.
*Әдәбият теориясе. Профессиональ җырчы.*
**III. Кадерле син, кеше-туганым!**
**Нәкый Исәнбәт.** Язучы турында кыскача белешмә.
**“Өч матур сүз” шигыре**. Әти-әни, туган илнең кадере. Шигырьдәге лирик герой. Шигырьнең диалог формасында язылуы. Шигырьнең Г.Тукайның “Туган тел” шигыре белән аваздашлыгы.
*Әдәбият теориясе. Лирик герой. Сынландыру.*
**Мәҗит Гафури.** Әдип турында кыскача белешмә. Рус мәсәлчеләре белән чагыштырып өйрәнү.
**«Әтәч белән Сандугач» мәсәле**. Мәсәлдә туган җир кадере темасының дәвам итүе. Ирек, кеше өчен ирек кадере турында белешмә. Мәсәлдә сынландыру алымы. Мәсәлнең морале.
**“Ана” шигыре**. Шигырьдә ана өчен бала, бала өчен ана кадере. Н.Исәнбәт шигырьләре белән аваздашлыгы. Бишек җырларының әһәмияте турында мәгълүмат.
*Әдәбият теориясе. Мәсәл.*
**Габдулла Тукай.** Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты турында мәгълүмат.
**“Шүрәле” экият-поэмасы.**Әкият-поэмада кеше һәм табигать мөнәсәбәтләре, туган авыл табигатенең матурлыгы. Шүрәле мифик образы. Әсәрдә егет һәм Шүрәле образларының бирелеше, аларга салынган мәгънә. Г.Тукай экиятләренә иллюстрацияләр авторы – Байназар Әлменов.
**Фәрит Яруллин.** Композитор турында белешмә.
**“Шүрәле” балеты.**Г.Тукайның «Шүрәле» экият-поэмасына балет язылу. Балет авторлары Ф.Яруллин, Ә.Фәйзи, Л.Якобсон турында мәгълүмат. Былтыр, Шүрәле образларының бирелеше. Сөембикә образы, аңа салынган мәгънә.
*Әдәбият теориясе. Балет.*
**Муса Җәлил.** Шагыйрьнең тормыш юлы, сугыш чоры иҗаты, “Моабит дәфтәрләре” турында мәгълүмат. М.Җәлилнең музей-квартирасы.
**“Чәчәкләр” шигыре.** Шигырьнең язылу урыны, вакыты. Шигырьдәге символлар. Ччәкләрнең матурлык һәм үлемсезлек символы буларак бирелүе. Туган илне ярату, туган илне саклау идеясе.
*Әдәбият теориясе. Символ, строфа.*
**Әмирхан Еники.** Әдип турында кыскача белешмә.
**“Туган туфрак” хикәясе.**Әсәрнең төп идеясе. “Нигез”, “туган туфрак” төшенчәләре. Авыл табигатенең, авыл халкының бирелеше. Хикәядәге символлар. Клараның эчке кичерешләре. Авыл проблемалары.
**IV. Энҗе карлар явып үткән...**
**Галимҗан Ибраһимов.** Әдип турында кыскача белешмә.
**“Кар ява” хикәясе.** Кышкы табигать, кар яву күренешенең тасвирлануы. Хикәядә чагыштырулар.
**Кави Нәҗми.** Шагыйрь турында кыскача белешмә.
**“Кызыклы хәл” шигыре.** Шигырьдә Вилдан белән булган хәлнең бирелеше. Строфа, рифмалар. Эчтәлекне ике өлешкә бүлеп карау мөмкинлеге. Шигырьдәге юмор.
**Мәрзия Фәйзуллина.** Тормыш юлы, иҗаты турында кыскача белешмә.
**“Чыршының күлмәкләре” шигыре.** Шигырьнең эчтәлеге, поэтик яңгырашы. Чагыштырулар, сынландыру. Шигырьдә күтәрелгән экология проблемасы.
**Резеда Вәлиева.** Шагыйрә турында кыскача мәгълүмат.
**“Нәни чыршы” шигыре.** Шигырьнең эчтәлеге, кулланылган троплар. Шигырьдә күтәрелгән проблема.
**Туфан Миңнуллин.** Тормыш юлы турында мәгълүмат (5 сыйныфта үткәннәргә өстәмә).
**“Акбай һәм Кыш бабай” пьесасы.**Пьесада Яңа ел бәйрәменә әзерлекнең бирелеше. Кыш бабай белән Кар кызы теләкләре. Яңа ел белән котлау сүзләре.

**V. Акыл — тузмас кием, белем — кипмәс кое.**

**Каюм Насыйри.** Әдип турында кыскача белешмә. Аның энциклопедист галим булуы. Казандагы һәм Яшел Үзән районындагы музейлары.

**“Әбүгалисина” кыйссасы.** Әбүгалисина һәм Әбелхарис образлары. Аларның белемгә омтылышлары, белем өйрәнүдәге тырышлыклары. Белемнең файдасы. Әбүгалисинаның ярлы егеткә, Әбелхарисның патшага булышуы. Туганлык һәм көнчелек хисләре. Әбүгалисинаның галим булып танылуы.

*Әдәбият теориясе. Кыйсса.*

**Габделхәй Сабитов.** Язучы турында кыскача белешмә.

**“Чүкеч” хикәясе.** Язучының әйтергә теләгән фикере. Хикәядә малай һәм ата образлары. Әсәрдә искә алынган эш кораллары.

*Әдәбият теориясе. Хикәяләү.*

**Абдулла Алиш.** Язучының тормыш юлы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат.

**“Әни ялга киткәч” хикәясе.** Хикәянең төп идеясе. Малайның яңага омтылышы, эшчәнлеге. Малайның өйдә башкарган эшләре. Малайның эшкә өйрәнүе турындагы мәкальләр.

*Әдәбият теориясе. Хикәяләүче.*

**Фәнис Яруллин.** Әдип турында кыскача белешмә.

**“Кояштагы тап” хикәясе.** Әсәрнең төп идеясе. Малай һәм ана образлары. Хикәядә ялганның, ялкаулыкның фаш ителүе. Яманлыкның эзе калуы.

*Әдәбият теориясе. Притча.*

**Гөлшат Зәйнашева.** Шагыйрә турында кыскача мәгълүмат.

**“Кем булырга?” шигыре.** Шагыйрәнең әйтергә теләгән фикере. Шигырьдә әйтелгән һөнәрләр. Һөнәр сайлауның мөһимлеге.

**Мәгъсүм Латыйфуллин.** Язучы турында кыскача белешмә.

**“Сәйдәшнең юл башы” хикәясе.** Салих Сәйдәшевның һөнәр сайлавында зур роль уйнаган вакыйга. Танылган кешеләрнең төрле һөнәрләр турында уйланулары. С.Сәйдәшевның тормышына йогынты ясаган шәхесләр.

*Әдәбият теориясе. Биографик әсәр.*

**Салих Сәйдәшев.** Композиторның тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. С.Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залы, музее, һәйкәле.

**Равил Фәйзуллин.** Шагыйрь турында кыскача мәгълүмат.

**“Бердәнбер” шигыре.** Шигырьнең төп идеясе. Бердәнбер сүзенең мәгънәсе. Шигырьнең төзелеше.

**VI. Ил өстендә илле дустың булсын.**

**Дәрдемәнд.** Әдип турында кыскача белешмә.

**“Ике туган” хикәясе.** Хикәянең эчтәлеге. Туганлык мөнәсәбәтләренең бирелеше. Әтәч белән тавыкның кешеләштереп (персонификация) бирелүе. Сәламәт булуның, куркынычсызлыкның элементар кагыйдәләре.

**Һади Такташ.** Шагыйрь, аның балачагы турында мәгълүмат.

**“Мокамай” поэмасы.** Поэманың эчтәлеге. Мокамай образының прототибы. Поэмада кулланылган сурәтләү чаралары. Тормыштагы ялгыш адымның һәлакәткә илтүе. Шагыйрьнең дуслык хисләренә тугрылыгы. Поэмадагы символлар.

*Әдәбият теориясе. Поэма.*

**Ренат Харис.** Әдип турында кыскача белешмә. Аның төрле яклы иҗаты.

**“Серле алан” пьесасы.** Пьесаның эчтәлеге. Малайлар, карт образлары. Пьесадагы символик образлар. Ваемсызлык нәтиҗәләре. Бәхет, тынычлык өчен һәр кешенең җаваплылыгы.

*Әдәбият теориясе. Символик образ. Диалог. Монолог.*

**Эльмира Шәрифуллина.** Шагыйрә турында кыскача мәгълүмат.

**“Дуслык, чын дуслык!” шигыре.** Шигырьнең эчтәлеге, төзелеше. Дуслыкның көче турында уйлану. (*1 сәгать*)

**Шәүкәт Галиев.** Язучының тормыш юлы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат.
**“Дуслык балы” шигыре.** Шигырьнең эчтәлеге. Шигырьдә күтәрелгән милләтара дуслык, толерантлык проблемалары.
Шигырьнең строфалары, рифмалары, троплар.
**VII. Көлке көлә килә...**
**Шәүкәт Галиев. “Курыкма, тимим”, “Атлап чыктым Иделне” шигырьләре.** Шигырьләрнең эчтәлекләре. Һәр шигырьдәге юмор.
**Фаил Шәфигуллин.** Язучының тормыш юлы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат.
**“Ике тиен акча” хикәясе.** Хикәянең эчтәлеге. Марат образы. Хикәядәге юмор. Язучының юмор аша әйтергә теләгән фикере.
**VIII. Һәр фасылың гүзәл, табигать!**
**Роберт Әхмәтҗанов.** Шагыйрь турында кыскача мәгълүмат.
**“Иртә әле...” шигыре.** Шигырьдә табигать тасвиры. Кулланылган әдәби алымнар. Туган ил кадере.
*Әдәбият теориясе. Пейзаж.*
**Гәрәй Рәхим.** Шагыйрь турында кыскача мәгълүмат.
**“Апрель” хикәясе.** Әсәрнең эчтәлеге. Төп идеясе. Хикәядәге чагыштырулар. Автор игътибарны юнәлткән табигать кануны.
*Әдәбият теориясе. Портрет.*
**Гомәр Бәширов.** Язучының тормыш юлы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат.
**“Туган ягым – яшел бишек” повестеннән өзек.** Сабантуй турындагы өзекнең эчтәлеге. Сабантуй бәйрәменең тасвирлап бирелеше. Көрәшче егетләр, Хәкимҗан образлары. Сурәтләү чаралары. Сабантуй бәйрәме тарихы.
**Лотфулла Фәттахов.**
Рәссамның тормышы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат. “Сабантуй” картинасында сурәтләнгән табигать, авыл кешеләре.
**Балалар өчен чыга торган газета-журналлар.**
**“Сабантуй” журналы.** Журнал басылып чыгу тарихы. Журнал рубрикалары. Мәкаләләрнең эчтәлеге.

**Ятлау өчен тәкъдим ителә торган әсәрләр**

Уен җырлары.
Татарстан Республикасы Дәүләт гимны.
Н.Исәнбәт “Өч матур сүз”.
М.Җәлил “Чәчәкләр” (өзек).
Р.Вәлиева “Нәни чыршы”.
Э.Шәрифуллина “Дуслык, чын дуслык!”.

**Өстәмә уку өчен тәкъдим ителә торган әсәрләр**
(укытучы сайлавы буена)

«Су иясе», «Өй иясе», «Дедал белән Икар», “Албасты” мифлары.
Батулла. Албасты.
Әпипә.
Н.Исәнбәт. Туган ил.
И.Крылов. Ат белән Эт.
Г.Шамуков. Арыслан белән Куян.
Г.Морат. Чит тел. Сабан туе.
М.Җәлил. Тик булса иде ирек.
И.Юзеев. Бакчачы турында баллада.
Г.Хәсәнов. Иң кыен вакыт – шул...
Н.Арсланов. Минем кунагым.
Л.Шагыйрьҗан. Ап-ак икән эзләрем.

Йолдыз. Китапханәдәге бәхәс.
Җ.Дәрзаман. Бүләк.
Н.Измайлова. Кеше турында – кешегә.
Ф.Яруллин. Тугры дус.
Н.Дәүли. Салих Сәйдәшев пианиносы.
Н.Сладков. Дуслар-ахирәтләр.
Ф.Шәфигуллин. Акбай белән Карабай.
Г.Остер. Серне ачты.
Н.Мадьяров. Урман аланына баргач.
Г.Рәхим. Беренче күкрәү.
Б.Рәхмәт Сабан туенда.

**7нче сыйныф**

**7 нче сыйныф укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:**

– әдәби әсәрләрне, сүзләрен дөрес әйтеп, йөгерек уку;
– авторның әйтергә теләгән фикерен аңлау, үз мөнәсәбәтен белдерү, әсәрне өлешләргә бүлә һәм планын төзи белү;
– әдәби-теоретик төшенчәләрне рус әдәбияты белеме белән тәңгәлләштерү;
– татар әдәбиятының дөнья культурасында тоткан урынын аңлау;
– авторларның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача күзаллау;
– 10—12 татар, рус, чит ил язучы, шагыйрьләренең исемнәрен һәм алар язган әсәрләрне белү;
– 4 – 5 сәнгать әһеленең тормышы, иҗаты турында мәгълүматлы булу;
– Казан һәм Татарстан төбәгендәге мәдәният учаклары (музей, театр, концерт залы һ.б.), балалар матбугаты турында белү;
– төрле халыкларның фольклор үрнәкләрен татар халык авыз иҗаты белән чагыштыру;
– 6 мәкаль, 6 әйтемне русча эквивалентлары белән истә калдыру;
– төрле авторларның 3 – 4 шигырен яттан сөйли белү;
– сүзлекләр, энциклопедияләр, интернет-ресурслардан файдаланып, үзенә кирәкле материалны табу;
– төрле темаларга проект эше яклау;
– әдәби әсәрне тормыш белән бәйләп, үз гамәлләренә бәя бирү.

**Курс темаларының эчтәлеге**

**Өйрәнелергә тиешле әсәрләр минимумы**

1. Г.Тукай «Милли моңнар».
2. Г.Ибраһимов «Алмачуар» (хикәядән өзек) .
3. С.Хәким «Бакчачылар».
4. Һ.Такташ «Алсу».
5. Г.Кутуй «Сагыну».
6. М.Мәһдиев «Без — кырык беренче ел балалары» (повестьтан өзек).
7. М.Галиев «Нигез» (повестьтан өзек) .

**Искәрмә:** минимумнан тыш өстәмә уку материалын сайлау мөмкинлеге, укытучы карамагында кала. Биредә мәктәпнең уку планында һәм еллык календарь графигында исәпкә алынаган сәгатьләр истә тотыла.

**I. Халык авыз иҗаты. Йола фольклоры.** Йола фольклоры турында төшенчә. Йолаларның төрләре. Алар – халыкның рухи байлыгы, халыкны милләт итеп берләштерә

торган асыл нигезләрнең берсе. Аларның көнкүреш һәм дини гореф-гадәтләр белән бәйләнеше, төрләре, үзенчәлекләре.

**Гаилә йолалары.** “Бәби туе”, “Туй” йолалары турында белешмә. Аларны үткәрү тәртибе.

**Фәтхи Бурнаш.** Язучы турында белешмә. “Яшь йөрәкләр” драмасы (өзек). Драмада йолаларның бирелеше, халкыбызга хас сыйфатлар.

**Халык авыз иҗаты. Бәетләр.** Бәетләрнең лиро-эпик жанр булуы. “Сак-Сок” бәете.Кошларга әйләнгән ике бала язмышының фаҗигасе, бәетнең фантастик сюжетка корылган булуы.

**Мөнәҗәтләр.** Мөнәҗәтләрнең лирик жанр булуы, аларның нигезендә ялгызлыкта үз-үзең белән сөйләшү, Илаһи көчкә мөрәҗәгать итү, ялварып, ярлыкауны сорау икәнлеге турында мәгълүмат. Мөнәҗәтләрнең борынгы заманнардан ук татар язма әдәбиятының һәм халык иҗатының үзенчәлекле жанры булып формалашуы. “Туган ил исемнән китмәс” мөнәҗәтендә туган ил темасының бирелеше.

**Габдулла Тукай.** Шагыйрь иҗаты турында белешмә.“Милли моңнар” шигыре. Шагыйрь һәм милләт язмышы мәсьәләсе.

**II. Аталар сүзе — акылның үзе**

**Фатих Әмирхан.** Тормышы һәм иҗади эшчәнлеге.“Ай өстендә Зөһрә кыз” әсәренең татар халык әкиятләренә нигезләнүе. Яхшылык белән явызлык көрәше.

*Әдәбият теориясе. Әдәбиятта фольклоризм.*

**Нәкый Исәнбәт.** Язучы иҗаты турында белешмә.Халык авыз иҗатын җыюдагы хезмәтләре. “Җирән чичән белән Карачәч сылу” драмасы. Үзәк геройда халык авыз иҗатыннан килә торган сыйфатларның (җорлык, тапкырлык, акыл көче ярдәмендә дошманнарын җиңү) туплап бирелеше.

**Галимҗан Ибраһимов.** Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Алмачуар” хикәясе. Хайваннарга карата миһербанлылык хисләре тәрбияләү.

**Татар халкының милли киемнәре һәм бизәнү әйберләре.** Түбәтәй (кәләпүш), калфак, читек, чулпы, беләзек, изү турында мәгълүмат. Милли киемнәрнең үзенчәлеге, вакыт узган саен үзгәрүләргә бирелүе, халкыбыз үткән зур тормыш юлын, аның үткәнен һәм бүгенгесен чагылдыруы.

**Роберт Миңнуллин.** Шагыйрь турында белешмә.“Килен төшкәндә” шигыре. Халкыбызның гореф-гадәтләрен белү, аларга мәхәббәт тәрбияләү.

**Рөстәм Яхин.** Композиторның тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Аның профессиональ җырлар, романслар, музыкаль әсәрләр башкаруындагы эшчәнлеге. Рөстәм Яхин – Татарстан Республикасының Дәүләт гимны авторы.

**Халисә Мөдәррисова.** Шагыйрәнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Көмеш дага” шигырендә бәхет төшенчәсенең тирән фәлсәфәсен ачуы. Сугыш фаҗигасенең чагылышы.

**III. Ил язмышы — ир язмышы**

**Әдип Маликов.** Шагыйрь турында белешмә. «Ил язмышы — ир язмышы” шигырендә ватанпәрвәрлек билгеләре чагылу. Шигырьдә оптимистик рух.

*Әдәбият теориясе. Гражданлык лирикасы. Пафос.*

**Гадел Кутуй.** Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Сагыну” нәсере. Сугыштагы кешенең кичерешләрендә туган ил образы.

*Әдәбият теориясе. Нәсер турында төшенчә. Инверсия.*

**Сибгат Хәким.** Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Бакчачылар” поэмасы, “Бу кырлар, бу үзәннәрдә” шигыре. Әсәрләрдә лиризм, сәнгатьчә гадилек һәм осталык, ватанпәрвәрлек хисләре чагылышы.

**Рафаил Төхфәтуллин.** Язучы турында белешмә. “Җиләкле аланнар” повестенда балачак хатирәләренең самимилеге, төгәллеге. Мәктәп тормышының үзенчәлекле детальләрдә чагылышы. Укучы һәм укытучы мөнәсәбәтләрен бала күңеле һәм хисләре аша тасвирлау.

**Мөхәммәт Мәһдиев.** Язучы турында белешмә. “Без — кырык беренче ел балалары” повесте (өзек). Бөек Ватан сугышы авырлыкларының әсәрдә чагылышы. Яшүсмерләр образы.

*Әдәбият теориясе. Тартмалы композиция.*

**Мөхәммәт Мирза.** Шагыйрь турында белешмә. “Изге сукмак” шигыре. Балачак хатирәләренең онытылмавы, кешелеклелек сыйфатларының (мәрхәмәтлелек, изгелек, шәфкатьлелек) бирелеше.

**IV. Һәр чорның үз герое**

**Нәҗип Думави.** Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Беренче кар” шигыре. Табигатьнең матурлыгын тасвирлау.

**Һади Такташ.** Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Алсу” поэмасы. Яшәү шатлыгы, оптимизм, үзеңне бәхетле тою хисләре чагылышы.

*Әдәбият теориясе. Рефрен, кабатлау.*

**Хәсән Туфан.** Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә.“Агыла да болыт агыла”, “Тамчылар ни диләр?” шигырьләре. Чор белән бәйле шәхес фаҗигасе, хаксызга рәнҗетелгән кешеләр язмышы.

**Гурий Тавлин** Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. **“**Кояш болытка кергәндә” романы (өзек). Әсәрдә фаҗигале елларның чагылышы. Чорның гаделсезлеген үз җилкәсендә татыган бала образы.

**V. Туган җир ул була бер генә, туган җирнең кадерен бел генә!**

**Аяз Гыйләҗев.** Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Өч аршын җир” повестеннан өзек. Туган җирнең кадерле булуы. Читтә яшәүчеләрнең туган туфракка тартылуы.

**Илдар Юзеев.** Шагыйрь турында белешмә. **“**Ак калфагым төшердем кулдан...” драмасы. Чит илләрдәге милләттәшләребез язмышы.

*Әдәбият теориясе. Ремарка.*

**Фәннур Сафин.** Шагыйрь турында белешмә. “Туган җиремә” шигыре. Туган якны ярату хисләренең бирелеше.

**Марсель Галиев.** Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Нигез” повесте (өзек). Әсәрдә Бөек Ватан сугышы елларындагы вакыйгалар. Повестьта гореф-гадәтләрнең, йолаларның бирелеше. Туган җирнең, туган нигезнең кадерле, изге булуы, образларның бирелеше.

*Әдәбият теориясе. Повесть.*

**VI. Актыктан хаклык җиңә**

**Фатих Хөсни.** Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Сөйләнмәгән хикәя” әсәре. Баланың күңел дөньясын сурәтләүдә язучының осталыгы. Мавыгу төшенчәсенә салынган мәгънәне ачыклау, үзеңә-үзең хуҗа булуның мөһимлеге.

*Әдәбият теориясе. Тема турында төшенчә.*

**Роза Хафизова.** Язучы турында белешмә. **“**Әти кайткан көн” хикәясе. Бөек Ватан сугышы чорында балалар язмышы.

**Фәнис Яруллин.** “Ак төнбоек” хикәясе. Кешегә яхшылык эшләүнең күркәм гадәт икәнен, әмма аны һәрчак искә төшереп торуның кире тәэсир ясавын оста күрсәтү.

**Рафис Корбан.** Шагыйрь турында белешмә. “Ярдәм итик” шигыре. Бал кортлары образы мисалында хезмәткә мәхәббәт тәрбияләү.

**Рөстәм Галиуллин**. Язучы турында белешмә. “Биш «икеле» хикәясе. Укуга, белем алуга уңай мөнәсәбәт тәрбияләү, кимчелекләрне юмор аша күрсәтү.

**Айгөл Әхмәтгалиева.** Язучы турында белешмә. “Табыш” хикәясе. Бала психологиясенең бирелеше, күркәм сыйфатлар тәрбияләү. Табылган әйбернең шатлык китермәвен аңлау.

**VII. Табигатькә дә табиб кирәк!**

**Мөдәррис Әгъләмов.** Шагыйрь турында белешмә. “Сөйли ак каен...” шигыре. Җанландырылган табигать образлары. Экологик тәрбия.

**Зиннур Мансуров**. Шагыйрь турында белешмә. “Балык кычкыруы” шигыре. Елга-күлләребезнең пычрануы - кешелек дөньясы өчен зур фаҗига. Табигатькә сакчыл караш тәрбияләү.

**Хәбир Ибраһим.** Язучы турында белешмә. **“**Карач” хикәясе. Кешеләрнең табигатьтәге җан ияләренә мөнәсәбәте.

**Ятлау өчен тәкъдим ителә торган әсәрләр**

Г.Тукайның “Милли моңнар” шигыреннән өзек.

Г.Кутуйның “Сагыну” нәсереннән өзек.

М.Мәһдиевнең “Без – кырык беренче ел балалары” повестеннан өзек.

Һ.Такташның “Алсу” поэмасыннан өзек.

Х.Туфанның “Агыла да болыт агыла” шигыреннән өзек.

**Дәрестән тыш (өстәмә) уку өчен тәкъдим ителә торган әсәрләр**

(укытучы сайлавы буена)

Мостай Кәрим. Озын-озак балачак.
Нардуган (Татар халык йоласы) .
Покрау (Керәшен татарлары бәйрәме).
Уярня (Мари халык бәйрәме).
Ким Васин. Җыр шулай туды.
Әмирхан Еники. Җиз кыңгырау.
Юрий Семендер. Ике ветеран.
Гәрәй Рәхим. Буыннар елъязмасы.
Марс Шабаев. Күңелемә, әткәй, кайтып кер...
Нәҗип Думави. Габдулла.
Гөлшат Зәйнашева. Үз илемдә.
Фоат Садриев. Юкка көттеләр.
Айрат Суфиянов. Мәктәптән кайтып килеш.
Гавриил Троепольский. Акбай Караколак.
Зиннур Мансуров. Ятим Су анасы.
Гомәр Бәширов. Җидегән чишмә.
Шәйхи Маннур. Печән җыйганда.
Рашат Низами. Куркытылган поши.

**Сөйләшү тематикасы**

Халыкның борынгыдан килгән йолалары.
Тукайлы тормыш.
Асылташларга тиң хәзинәләр.
Халык авыз иҗатының әдәбиятта чагылышы.
Батырлар бар төштә – татарлар бар...
Ватан барыннан да газиз.
Балачакның онытылмас мизгелләре.
Табигать – уртак йортыбыз.

**8нче сыйныф**

**8 нче сыйныф укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр**

− әдәби әсәрләрне, сүзләрен дөрес әйтеп, йөгерек уку;

− авторның әйтергә теләгән фикерен аңлау, үз мөнәсәбәтен белдерү, әсәрне өлешләргә бүлә һәм планын төзи белү;

− әдәби-теоретик төшенчәләрне рус әдәбияты белеме белән тәңгәлләштерү;

− татар әдәбиятының һәм тарихи мәгълүматларның дөнья культурасында тоткан урынын аңлау;

− авторларның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача күзаллау;

− 11—12 татар, рус, чит ил язучы-шагыйрьләренең исемнәрен һәм алар язган әсәрләрне белү;

− 5—6 сәнгать әһеленең тормышы, иҗаты турында мәгълүматлы булу;

− Казан һәм Татарстан төбәгендәге мәдәният учаклары (музей, театр, тыюлык, концерт залы һ.б.), балалар матбугаты турында белү;

− төрле халыкларның фольклор үрнәкләрен татар халык авыз иҗаты белән чагыштыру;

− 7 мәкаль, 7 әйтемне русча эквивалентлары белән истә калдыру;

− төрле авторларның 3—4 шигырен яттан сөйли белү;

− сүзлекләр, энциклопедияләр, Интернет-ресурслардан файдаланып, үзенә кирәкле материалны табу;

− төрле темаларга проект эше яклау;

− әдәби әсәрне тормыш белән бәйләп, үз гамәлләренә бәя бирү.

## Курс темаларының эчтәлеге

**Өйрәнелергә тиешле әсәрләр минимумы**

1) Г.Тукайның “Пар ат” шигыре;
2) Ш.Камалның “Буранда” новелласы;
3) С.Хәкимнең “Җырларымда телим” шигыре;
4) Г.Афзалның “Юл газабы” хикәясе;
5) Ф.Садриевның “Таң җиле” романыннан өзек;
6) Р.Харисның “Ике гөл” шигыре;
7) Т.Миңнуллинның “Моңлы бер җыр” драмасыннан өзек.

**Искәрмә:** минимумнан тыш өстәмә уку материалын сайлау мөмкинлеге, укытучы карамагында кала. Биредә мәктәпнең уку планында һәм еллык календарь графигында исәпкә алынаган сәгатьләр истә тотыла.

### I. Тарих китабында безнең өчен бик күп хатирәләр саклана

**Халык авыз иҗаты.** Фольклор жанрлары буларак риваятьләр, аның ничек барлыкка килүе. Риваять төрләре.

**Тарихи риваятьләр.** *Татар халыкының “Сихерче кыз” риваяте.* Әсәрдә Казан образының бирелеше, тарихы. Әлеге риваятькә хас әкияти алымнар.

*Топонимик риваятьләр.* Татар халкының “Гали тугае” риваяте. Урта гасыр Европа халкының “Моргана”риваяте. *Шәһәр, авыл, тау һәм елга атамаларының килеп чыгышы.*

*Легендалар. Аның төрләре. Легенданың риваятьтән аермалы яклары.*

**Татар халкының «Зөһрә кыз» легендасы.** Легендада Зөһрә образының бирелеше. Әсәрдә хыял мотивлары, аның кеше язмышын ачудагы роле. Әсәрдә гаиләдәге мөнәсәбәтләрнең бирелеше..

Музыка уен кораллары, аларның халык тормышындагы роле.

### II. Без тарихта эзлебез

**Тарихи ядкарьләр буларак сәяхәтнамә һәм елъязма жанрлары. Ибне Фадлан** – X гасырның беренче яртысында яшәгән гарәп сәяхәтчесе. Ибн Фадланның 921 – 922 нче елларда Болгар дәүләтенә сәфәре вакытында язылган сәяхәтнамәсе. Болгар дәүләтенең ил тарихындагы роле. Ил башлыгы Алмыш хан.

**Фатих Кәрими.** Әдип һәм журналист тормышы һәм иҗат юлы. Аның Европа илләренә сәяхәте, бу сәяхәтнең максаты. «Аурупа сәяхәтнамәсе» әсәреннән өзек. Европа илләрендәге культура учаклары, Петербург китапханәсе турында мәгълүмат. «Аурупа сәяхәтнамәсе»нең әдәби роле.

**Миргазиян Юныс**. Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Татар әдәбиятында диңгезчелек (маринистика) жанрына нигез салуы. Язучының “Су” хикәясе.

*Әдәбият теориясе. Тарихи роман турында төшенчә.*

Тарихи һәйкәл буларак **Казан Кремле**, аның төзелү тарихы. Кремльнең бүгенге торышы.

**Габдулла Тукай.** Язучының 1895 нче елда Җаек (Уральск) шәһәренә китүе. Анда Тукайның җәмәгать эшлеклесе, журналист, тәрҗемәче һәм шагыйрь буларак формалашуы. 1907 нче елда кире Казанга кайтуы. Шагыйрь иҗатының Казан чоры. Казанда аралашкан дуслары, балалар әдәбиятына һәм халык әдәбиятын өйрәнүгә керткән өлеше, театр эшчәнлегенә игътибары, сәяхәтләре, иҗтимагый эшчәнлеге. “Әл-ислах” газетасындагы эшчәнлеге. Габдулла Тукайның “Пар ат” шигыре. Аның язылу тарихы. “Пар ат” шигыренең лирик герое, аның кичерешләре, өметләре. Пар ат образының символикасы. Табигать, кучер образларының бирелеше, мәгънәләре.

**Бакый Урманченың** “Пар ат” шигыренә иллюстрациясе. Картинада Габдулла Тукай шигырендә сурәтләнгән вакыйганың бирелеше.

**Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе. Премиянең беренче лауреатлары.**

Күренекле рәссам, сынчы **Бакый Урманченың** (1897 – 1990) тормышы. Ул тудырган скульптур портретлар, картиналар.

**Нажар Нәҗми.** Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы. Аның Тукай шәкерте булуы, аның идеяләрен үстерүе. Н.Нәҗми иҗат иткән әсәрләрдә Тукай образының бирелеше, мәгънәсе. Шагыйрьнең «Татар теле» әсәрендә Тукай традицияләрен дәвам итүе. Н.Нәҗминең Бөек Болгарга сәфәре турындагы “Агыйделдә ак пароход” әсәреннән өзек. Әсәрдә сурәтләнгән “түгәрәк өстәл”, анда катнашкан язучылар. Әсәрнең әдәби мәгънәсе, кыйммәте.

**III. Онытылмас еллар**

**Гариф Ахунов.** “Замандашлар портреты” әсәреннән өзек. Язучының әсәрдә рәссам Виктор Куделькинның иҗатын яктыртуы, аның картиналары турында уйланулары. Рәссам иҗатында М.Җәлил образы, аның бирелеше, иҗатчының халык язмышының кискен дәверләрен полотнода сурәтләве. В.Куделькинның “Билгесез биеклектә” картинасы, Бөек Ватан сугышы.

**Сугыш турындагы җырлар.** Роберт Әхмәтҗановның “Озатып вокзаллар каршында…” (“Солдатлар”) шигыре. Сугышка баласын озаткан Ана образы. Татар халкының “Герман көе” җыры. Музыка сәнгатенең матур әдәбият белән тыгыз бәйләнештә булуы һәм бер-берсенә йогынтысы.

**Фатих Кәримнең** тормышы, иҗаты. Аның иҗатында сугыш темасы, образларның бирелеше. Шагыйрьнең “Ант” шигыре, «азатлык» һәм «явызлык» проблемалары. “Кыңгыраулы яшел гармун” поэмасы, андагы образлар системасы. Гармун һәм җыр образының роле. Әлеге лирик әсәрләрдә сугыш проблемасының бирелеше.

**Туфан Миңнуллин**. Күренекле драматург, язучы, публицист һәм җәмәгать эшлеклесенең тормышы һәм иҗаты. “Моңлы бер җыр” драмасы. Әсәрдә М.Җәлил образының бирелеше, аның тоткынлыктагы тормышы. Драмада фәлсәфи мотивлар, фантастик алымнарның роле. Т.Миңнуллинның “Моңлы бер җыр” публицистик драмасы турында белешмә.

**Казанда Муса Җәлил һәйкәле һәм җәлилчеләргә куелган барельефлар.**

**Марсель Сәлимҗанов**. Режиссёрның тормышы, иҗаты. Аның татар профессиональ театрының, милли драматургиянең үсешенә керткән өлеше.

**Ринат Тажетдинов.** Халык артистының тормышы һәм иҗаты, ул тудырган онытылмас образлар.

**Фронт хатлары**, аның халык тормышындагы роле. Муса Җәлилнең кызы Чулпанга язган хаты, Фәтих Кәрим хатлары. Татар әдәбиятында эпистоляр жанр.

*Әдәбият теориясе. Эпистоляр жанр турында төшенчә.*

**Мостай Кәрим.** Шагыйрь һәм язучының тормышы, иҗаты. “Билгесез солдат” шигыре. Шигырьдә билгесез солдат образы. Лирик геройның кичереше, шәхесләр язмышы.

**Чыңгыз Айтматов.** Әдип турында белешмә. Аның “Анам кыры” әсәре. Әсәрдә Тулганай, Җир-ана образлары. Җыелма Җир-ана образына салынган мәгънә. Авторның сугыш турындагы уйланулары. «Анам кыры» повесте турында белешмә.

**Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау**.

**IV. Әтинең зур бүреге иртә киелде**

**Клара Булатова.** Шагыйрә турында белешмә. “Башым иям” шигыре, сугыш афәтенең шагыйрәнең балачагына тәэсире, хатирәләрендә калдырган эзе.

**Нур Әхмәдиев.** Язучы иҗаты турында белешмә. “Җиңү көне” шигыре. “Минем туган көнем” хикәясе..

**Факил Сафин.** Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Тулганай” әсәреннән өзекләр. Тулганай образы, аның әсәрдәге башка образларны ачудагы әһәмияте. Әсәрдә кешелеклек, шәфкатьлелек проблемалары.

**Разил Вәлиев.** Тормышы һәм иҗади эшчәнлеге. “Ватаным” шигыре. Сугыш, аның гади халык, балалар җилкәсенә алып килгән авырлыгы.

**Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау**.

**V. Ана — изге, Ана — бөек, аңа — дан!**

**Аңлар өчен йөрәгенең олылыгын,**

**Туу кирәк кайчак безгә яңадан!**

**Шәриф Камал.** Әдипнең тормышы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат. “Буранда” новелласы. Төп геройның язмышы. Аның эчке дөньясы, күңел халәте. Психологик алымнар. Әсәрдә Ана образына хас сыйфатлар.

*Әдәбият теориясе. Әдәби деталь. Матур әдәбиятта психологизм. Новелла турында төшенчә.*

**Ибраһим Салахов.** Язучының тормышы һәм иҗаты. Репрессияләнгән әдипләр язмышы. “Халык дошманы” төшенчәсе. “Ана тавышы” хикәясе (“Колыма хикәяләре” циклыннан). Ялгыз ананың аяныч язмышы, кичерешләре. Автор әйтергә теләгән фикер.

**Сибгат Хәким.** Шагыйрьнең тормыш юлы**,** иҗаты турында мәгълүмат. Иҗатында яктырткан темалар. “Әнкәй” шигырендә Ана образына хас сыйфатлар. Лирик геройның хис-кичерешләр бирелеше. Сагыну хисе. “Җырларымда телим” шигыре. Шигырьнең эчтәлеге, поэтик яңгырашы, сурәтләү чаралары. Шигырьдә күтәрелгән проблемалар.

**Роберт Миңнуллин.** Әдипнең тормыш юлы, иҗаты. Әдәбиятка булган мәхәббәте. Иҗатында яктыртылган темалар. “Әнкәй” шигыре. Ана образының бирелеше. Лирик геройның уйлары, кичерешләре.

**Марсель Галиев.** Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты турында мәгълүмат. “Су буеннан әнкәй кайтып килә” шигыре. Шигырьдә ана образы. Лирик геройның туган ягы турында хис-кичерешләре. “Кабатланмас әкият” шигыре. Хыялда туган авыл күренеше. Балачакка кайту теләге, лирик геройның хис-кичерешләре. Ана образының бирелеше **Луиза Батыр-Болгари.** Композиторның тормыш юлы, иҗаты.

**Шәриф Хөсәенов.** Әдипнең тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат. Беренче драмалары турында белешмә. “Әниемнең ак күлмәге” (“Әни килде”) драмасы. Драмада ана образының бирелеше. Ананың язмышы, балаларына булган мәхәббәте. Автор әйтергә теләгән фикер. Шәриф Хөсәеновның “Әниемнең ак күлмәге” (“Әни килде”) драмасы турында. Драманың татар әдәбиятында тоткан урыны. Ана образы турында мәгълүмат. Аналар һәм балалар проблемасы.

**Фоат Садриев.** Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Таң җиле” романы. Романда бирелгән образларның язмышы, ана (Нуриәсма) образының бирелеше.

Нәсимә белән Фәритнең үз-үзләрен тотышы, уллары Маратның авылда терелүе, сөйләшә башлавы, дуслар табуы. Авторның әйтергә теләгән фикере.

**Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау**.

**VI. Көлсәң – көл, еласаң – ела!**

**Беренче сатирик журналлар.** Беренче сатирик журналлар турында белешмә. Вакытлы матбугатны башлап җибәргән шәхесләр.

*Әдәбият теориясе. Сатира турында төшенчә.*

**Галиәсгар Камал.** Әдипнең тормыш юлы, иҗаты, татар әдәбиятында тоткан урыны. **"Банкрот" сатирик комедиясе.** Сираҗетдин Туктагаевның тормыш, көнкүреше, уйлаган хәйләсе. Тирә-юньдәге образларның үз-үзләрен тотышы. Галиәсгар Камалның "Банкрот" комедиясе турында белешмә. Әсәрнең сәхнә тарихы. Әдип тарафыннан күтәрелгән проблема.

*Әдәбият теориясе. Конфликт турында төшенчә. Сарказм. Проза әсәрләрендә сатира.*

**Гамил Афзал.** Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат. Юмор-сатира өлкәсендә тоткан урыны "Юл газабы" хикәясе. Хикәяләүче авторның язмышы турында белешмә. "Тәвәккәл әби" шигыре. Әбинең аянычлы язмышы, эш-гамәлләре. Шигырьнең эчтәлеге, поэтик яңгырашы. Автор идеясе. Сурәтләү чаралары. Шигырьдә күтәрелгән проблемалар.

*Әдәбият теориясе. Сатирик шигырь. Ирония турында төшенчә.*

**Зәки Нури.** "Пародия". Пародиянең язылу стиле. Пародиягә салынган эчтәлек. Төрле шәхесләргә багышланган эпиграммалар. Эпиграммаларда сарказм.

*Әдәбият теориясе. Пародия турында төшенчә. Эпиграмма.*

**Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау**.

**VII. Даһи гомере – халкы хәтерендә!**

**Ренат Харис.** Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. "Гармунчы" поэмасы. Поэманың эчтәлеге. Лирик геройның бирелеше. Поэмада кулланылган сурәтләү чаралары. Гармуннан чыккан көйләрнең сурәтләнеше. "Ике гөл" шигыре. Шигырьнең идеясе, төзелеше. Шигырьгә салынган мәгънә. Автор әйтергә теләгән фикер.

**Зөлфәт.** Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Юмор-сатира өлкәсендә ирешкән уңышлары. "Шигырем – ачык!" ,"Шундый чагы әле җанымның" шигырьләре. Аларда лирик геройның хис-кичерешләре. Әдип шигыренә хас үзенчәлекләр.

*Әдәбият теориясе. Документаль повесть жанры.*

**Галия Кайбицкая.** Актрисаның тормыш юлы турында белешмә. Татар музыка сәнгатен һәм операсын үстерүгә керткән өлеше.

**Рабит Батулла.** Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Төрле жанрларда иҗат итүе. "Бию" кыйссасы. Рудик белән бәйле, госпитальдә булган көлкеле вакыйганың әдәби гәүдәләнеше. Яшь талантның беренче уңышы.

**Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау**.

**VIII. Табигатьнең дә җаны бар.**

**Айдар Хәлим.** Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. "Өч аяклы ат" повесте. Әсәрнең эчтәлеге. Кәбирнең язмышы, атка мөнәсәбәте. Аның тирәсендә булган башка геройларның үз-үзләрен тотышы. Ат образының бирелеше.

**Гарәфи Хәсәнов.** Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. "Беренче күк күкрәү" хикәясе. Язгы табигать күренешенең сурәтләнеше. Геройның язгы табигать турында уйлары, хис-кичерешләре. Беренче күк күкрәү мизгелләренең тасвирланышы.

**Камил Кәримов.** Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. "Тимергали бабай хикәяте" хикәясе. Хикәянең эчтәлеге. Авторның Сабантуй бәйрәмен тасвирлау үзенчәлеге. Заманга хас булган атрибутларның бирелеше (кулъяулык бирү, аулак өй күренеше һ.б.).

**"Ялкын" журналы.** Журналның тарихы. Журнал рубрикалары. Мәкаләләрнең эчтәлеге.

**Ел дәвамында үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау.**

**Ятлау өчен тәкъдим ителә торган әсәрләр**

Г.Тукайның “Пар ат” шигыреннән өзек.
Ф.Кәримнең “Ант” шигыре.
Р.Вәлиевнең “Ватаным” шигыре.
С.Хәкимнең “Җырларымда телим” шигыре.
Р.Харисның “Ике гөл” шигыре.

**Дәрестән тыш (өстәмә) уку өчен тәкъдим ителә торган әсәрләр**

(укытучы сайлавы буена)

Мәҗит Гафури. “Хан кызы Алтынчәч”.
“Утсыз кайный торган казан” (Татар халык риваяте).
*“Казан кайда корылган” (*Татар халык *легендасы).*
“Гали тугае” (Татар халык риваяте).
*“Кәккүк каян барлыкка килгән?” (*Татар халык *легендасы).*
“Зөһрә кыз” (Татар халкы легендасы).
“Местер Стуруорм” (Борынгы шотланда легендасы).
Фәрит Яхин. “Һомай кошы”.
Әмирхан Еники. “Курай”.
Фәнис Яруллин. “Моңлы курай”.
Вахит Имамов. “Казан дастаны”.
Әхсән Баян. “Хыялда туган калам”.
Казанда Бакый Урманче музее.
Илһам Шакировның тормыш юлы, иҗаты.
Илдар Юзеев. “Һаман көтә”.
Рафаэль Мостафин. “Йөз ундүрт адым”.
Мансур Шиһапов. “Җиңү көне җиңел бирелмәде”.
Сибгат Хәким. “Клиндерләр эзлим”.
Роберт Миңнуллин. “Әнкәйнең ак чәчләре”.
Габдулла Кариев. Нурлат районы Күлбай Мораса авылында Габдулла Кариев музее.
Фатих Әмирхан. “Фәтхулла хәзрәт”.
Нәкый Исәнбәт. “Хуҗа Насретдин”.
Зыя  Мансур. “Таңсылу әкияте”.
Фирдәвес Әһлия. “Актриса”.
Зиннур Хөснияр. “Рәссам язмышы”.

**Сөйләшү тематикасы**

Халыкның борынгыдан килгән йолалары.
Әдәбиятта һәм сәнгатьтә Тукай образы.
Язучылар, шагыйрьләр тормышында сугыш.
Илебезгә җиңү килде!
Ана – бөек исем...
Табигать – уртак йортыбыз.

**9нчы сыйныф**

**9 нчы сыйныф укучыларының әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:**

– әдәби әсәрләрне, сүзләрен дөрес әйтеп, йөгерек уку;

– авторның әйтергә теләгән фикерен аңлау, үз мөнәсәбәтен белдерү, әсәрне өлешләргә бүлә һәм планын төзи белү;

– әдәби-теоретик төшенчәләрне рус әдәбияты белеме белән тәңгәлләштерү;

– татар әдәбиятының һәм тарихи мәгълүматларның дөнья культурасында тоткан урынын аңлау;

– авторларның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача күзаллау;

– 12—13 татар, рус, чит ил язучы-шагыйрьләренең исемнәрен һәм алар язган әсәрләрне белү;

– 6—8 сәнгать әһеленең тормышы, иҗаты турында мәгълүматлы булу;

– Казан һәм Татарстан төбәгендәге мәдәният учаклары (музей, театр, тыюлык, концерт залы һ.б.), балалар матбугаты турында белү;

– төрле халыкларның фольклор үрнәкләрен татар халык авыз иҗаты белән чагыштыру;

– 7–8 мәкаль–әйтемне русча эквивалентлары белән истә калдыру;

– төрле авторларның 4–5 шигырен яки әсәрдән өзекне яттан сөйли белү;

– сүзлекләр, энциклопедияләр, Интернет-ресурслардан файдаланып, үзенә кирәкле материалны табу;

– төрле темаларга проект эше яклау;

– әдәби әсәрне тормыш белән бәйләп, үз гамәлләренә бәя бирү.

## Курс темаларының эчтәлеге

**Өйрәнелергә тиешле әсәрләр минимумы**

1. Г.Тукайның “Татар кызларына” шигыре;
2. Ф.Әмирханның “Хәят” повестеннан өзек;
3. Г.Камалның “Беренче театр” комедиясе;
4. Г.Әпсәләмовның “Ак чәчәкләр” романыннан өзек;
5. А.Гыйләҗевнең “Җомга көн, кич белән...” повестеннан өзек;
6. Р.Мингалимнең “Сап-сары күзләр” хикәясе;
7. Р.Әхмәтҗановның “Сандугач керде күңелгә” шигыре.

**Искәрмә:** минимумнан тыш өстәмә уку материалын сайлау мөмкинлеге, укытучы карамагында кала. Биредә мәктәпнең уку планында һәм еллык календарь графигында исәпкә алынаган сәгатьләр истә тотыла.

**I. Атадан улына чын мирас – сүздер**

**Халык авыз иҗаты. Дастаннар.**

Халык авыз иҗатының эпик жанры дастан турында төшенчә. Дастаннарның төрләре. “Идегәй” дастаны. Аның төп герое. Дастанда тарихи шәхесләрнең сурәтләнүе. Әсәрдә ил белән идарә итү, халык язмышы мәсьәләсе.

*Әдәбият теориясе. Халык авыз иҗаты. Дастан. Трагедия.*

**Кол Гали** язмышы. Аның “Кыйссаи Йосыф” поэмасы. Йосыфның язмышы. Туганнар арасындагы мөнәсәбәтләр. Йосыф-Зөләйха мәхәббәте. Сюжетта кешеләрне ярату (гуманизм), гаделлек карашларының чагылышы. Поэмада төш күрү мотивлары.

*Әдәбият теориясе. Рәдиф.*

**Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатла**.

**II. Мәхәббәт бер булса да, ике йөрәктә яши**

**Сәйф Сараи** иҗаты. Аның “Сөһәйл вә Гөлдерсен” дастаныннан өзек. Әсәрнең сюжеты. Дастанда сурәтләнгән табигать күренешләренең роле. Чагыштыру, метафоралар, аларның оригинальлеге. Дөньяны материалистик аңлауны чагылдырган детальләр, аларның ышандыру көче. Геройларга характеристика бирү.

*Әдәбият теориясе. Нәзыйрәчелек.*

**Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау**.

**III. Гөл үссә – җирнең күрке,**

**Кыз үссә – илнең күрке**

**Габделҗаббар Кандалыйның** тормыш юлы һәм иҗаты. “Сахибҗамалга” поэмасы. Шагыйрьнең әдәбиятка алып килгән яңалыгы. Әсәрдә мәхәббәтнең чагылышы. Хатын-кыз гүзәллеген тасвирлауда шагыйрьнең табышлары.

**Ризаэтдин Фәхретдиннең** тормышы турында белешмә. “Әсма, яки Гамәл вә җәза” романында күтәрелгән проблемалар. Яхшылык һәм явызлык, әдәплелек һәм әдәпсезлек, галимлек һәм наданлык бәрелеше. Төп герой Әсма язмышы.

**Габдулла Тукайның** тормыш юлы һәм эшчәнлеге турында белешмә. Әдипнең Казан чоры иҗаты. “Татар кызларына” шигырендә күтәрелгән мәсьәләләр. Әсәрдә лирик геройның хисләрен ачыклау. Г.Тукайның татар кызлары турындагы хыял-өметләре. Шагыйрь һәм милләт язмышы мәсьәләсе. Казан шәһәрендә Габдулла Тукай музее турында мәгълүмат.

*Әдәбият теориясе. Антитеза.*

**Фатих Әмирханның** тормыш юлы һәм иҗаты. Әдипнең күпкырлы иҗаты. “Хәят” повесте. Төп каһарман образы. Аңа хас сыйфатлар. Бай татар зыялыларының гаилә тормышы һәм гореф-гадәтләре. Шул шартларда үскән татар кызының холкы тәрбияләнү, омтылыш-теләкләре чагылу. Рус дөньясы белән аралашып үскән яшь кешенең дөньяга һәм яшәү тәртипләренә карашында каршылыклар туу. Кеше психологиясен тасвирлауда авторның осталыгы.

**Аяз Гыйләҗевның** тормышы һәм иҗаты турында белешмә. Аның “Җомга көн, кич белән...” повесте. Әсәрдә Бибинур образының бирелеше. Бибинур әбинең изге күңеллелеге, шәфкатьлелеге. Авторның кешеләрдә яхшылык, игелеклелек кебек сыйфатларның кими баруына борчылуы. Повестьның А.Солжиницынның «Матрёнин двор» әсәре белән уртак һәм аермалы яклары. Әсәрнең сәнгатьнең башка төрләре белән бәйләнеше.

**Рөстәм Мингалим** иҗаты. Шагыйрьнең прозасы “Сап-сары көзләр” хикәясе. Сугыш чоры кешеләренең язмышы, тормышы сурәтләнеше.

**Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау**.

**IV. Бер йөрәктә туган җыр икенче йөрәкне кузгата**

*Әдәбият теориясе. Лирика. Пейзаж лирикасы.*

**Ркаил Зәйдулла** турында белешмә. “Буранда” шигырендә сурәтләнгән табигать күренеше. Шагыйрь хисләрен ачу юллары.

**Илсөяр Иксанова иҗаты.** “Тузганак” шигырендә пейзаж бирелеше. Анда табигать һәм кеше мөнәсәбәтләренең ачылышы.

*Әдәбият теориясе. Гражданлык лирикасы.*

**Сания Әхмәтҗанованың** тормыш юлы һәм иҗаты. Аның “Татар акылы...” әсәрендә күтәрелгән проблемалар. XX йөз башында Төркиягә киткән бөек шәхесләр турында мәгълүмат бирү.

*Әдәбият теориясе. Фәлсәфи лирика.*

**Марс Шабаев** тормышы һәм иҗаты. “Корыган имән монологы” шигырендә шагыйрьнең фәлсәфи карашларының чагылышы.

**Мөхәммәт Мирза** тормышы һәм иҗаты турында белешмә. Иҗатына хас үзенчәлекләр. Робагый, газәл жанрындагы әсәрләре.

*Әдәбият теориясе. Күңел лирикасы.*

**Фирүзә Җамалетдинованың** иҗаты. Аның “Ташлар”, “Кунак көткән кебек” шигырьләренең идея-проблематикасы.

**Рәшит Әхмәтҗанов** тормышы һәм иҗаты турында белешмә. “Сандугач керде күңелгә” шигырендә шагыйрь хисләренең чагылышы.

**Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау**.

**V. Театр – яктылыкка, нурга илтә!**

**Галиәсгар Камал тормышы һәм** иҗаты турында белешмә. Драматург каләменә хас сыйфатлар. “Беренче театр” комедиясендә конфликт һәм аның чишелеше, образларның үзенчәлекле якларын ачу.

*Әдәбият теориясе. Сүз уйнату. Монолог.*

Беренче хатын-кыз татар артисткасы **Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская** иҗаты, театр сәнгатен үстерүдәге эшчәнлеге.

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры турында белешмә.

**Халисә Мөдәррисованың** тормышы һәм иҗаты. “Бәйге хакы” повестеннан өзек белән танышу. Язучының кеше язмышы турындагы ачыш-табышлары. Артистлар тормышын яктыртудагы яңалыгы. Аның сәхнә әсәре булып уйналуы.

**Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау**.

**VI. Мең шифага ия кулларда**

**Күпме язмышларның эзе бар...**

**Габдрахман Әпсәләмовның тормыш юлы һәм иҗаты.** “Ак чәчәкләр” романында күтәрелгән проблемалар. Әсәрдә табиблар һәм шәфкать туташларының хезмәтен чагылдыру үзенчәлеге.

*Әдәбият теориясе. Роман. Хронотоп.*

**Саҗидә Сөләймәнованың тормышы һәм язмышы турында** белешмә. Әдинең шигъри осталыгы. Шагыйрәнең прозасы. Табиблар тормышын чагылдырган “Гөлбадран” повестеннан алынган “Дөнья бу!..” өзеге белән танышу. Сәламәтлек сагында торучы табибларның үз эшләренә һәм кешеләргә мөнәсәбәте. Медицинада хирург хезмәте турында сөйләшү.

**Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау**.

**VII. Укытучым! Синең бөек исемең**

**Йөрәгемдә мәңге сакланыр...**

**Мөхәммәт Мәһдиевнең** тормыш юлы һәм иҗаты. Әдип каләменә хас сыйфатлар. “Фронтовиклар” романында укытучылар тормышын һәм эшчәнлеген чагылдыру үзенчәлеге. Төп герой Рушад образы.

*Әдәбият теориясе. Тип.*

**Рәдиф Гаташның** тормышы һәм иҗаты турында белешмә. Аның шигъри осталыгы. Әсәрләренең жанры. “Укытучы” шигыре.

**Лена Шагыйрьҗанның** тормыш юлы һәм иҗаты. Шигърияткә алып килгән яңалыгы. “Укытучы” шигырендә күтәрелгән проблемалар.

**Вакыйф Нуриевның** тормыш юлы һәм иҗаты. “Инша” хикәясендә Әкрәм образының бирелеше. Хикәядәге юморны аңлау.

**Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау**.

**VIII. Авыр эшкә беләк бар,**

**Кыю эшкә йөрәк бар**

**Хәсән Сарьянның** тормыш юлы һәм иҗаты. Иҗатында лиризм. “Әткәм һөнәре” повестенда яшь кеше образын ачу үзенчәлекләре, аларда әхлакый сыйфатларның бирелеше. Татар халкының борынгыдан килгән һөнәрләре турында белешмә бирү.

**Гариф Ахуновның** тормышы һәм иҗаты турында белешмә. Иҗатында нефтьчеләр тормышын яктырту үзенчәлекләре. “Хәзинә” романында нефть чыгаручылар образлары. Нефть табу белән бәйле һөнәрләр турында мәгълүмат бирү.

*Әдәбият теориясе. Әдәби характер.*

**Илдар Юзеевның** тормыш юлы һәм иҗаты. Аның шигъри һәм драматурглык осталыгы. “Таныш моңнар” поэмасында яшь кешенең тормыш юлын сайлауны чагылдыру.

*Әдәбият теориясе. Поэма.*

**Хисам Камаловның** тормыш юлы һәм иҗаты. “Очучы” хикәясендә күтәрелгән проблемалар. Очучы һөнәре турында мәгълүмат бирү.

*Әдәбият теориясе. Мәдхия.*

**Мәдинә Маликованың** тормыш юлы һәм иҗаты. “Казан каласы – таш кала” повестенда архитекторлар һөнәренә хас сыйфатларны чагылдыру үзенчәлеге.

**Салисә Гәрәеваның** тормышы һәм иҗаты турында белешмә. Эшче һөнәрләрен ачу үзенчәлеге. “Сварщик егет” шигыре. Әдәбиятта тимерне эретеп ябыштыручылар образларын һәм эшчәнлеген гәүдәләндерү.

**Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау**.

**Ятлау өчен тәкъдим ителә торган әсәрләр**

Фатих Әмирханның “Хәят” повестеннан өзек.
Рәшит Әхмәтҗановның “Сандугач керде күңелгә” шигыре.
Галиәсгар Камалның “Беренче театр” комедиясеннән бер монолог.
Фәнис Яруллинның “Сез иң гүзәл кеше икәнсез” шигыре.
Илдар Юзеевның “Таныш моңнар” поэмасыннан өзек.
Нур Әхмәдиевның “Авылдашым” шигыре.

**Өстәмә уку өчен тәкъдим ителә торган әсәрләр**
(укытучы сайлавы буенча)

Юныс Сафиуллинның «Идегәй» трагедиясе.
Сайадиның “Таһир – Зөһрә” әсәреннән өзек.
Әхмәд Уразаев –Кормашиның “Таһир белән Зөһрә кыйссасы”ннан өзек.
Фәтхи Бурнашның “Таһир –Зөһрә” трагедиясеннән өзек.
Казанда Габдулла Тукай музее.
Сания Әхмәтҗанованың “Сүнмәс балкыш” шигыре.
Рәшит Әхмәтҗановның “Дөнья күрергә китү” шигыре.
“Сәйяр” труппасы турында мәгълүмат.
Канәфи Нәфыйковның “Тукай чәчәге” картинасы.
Казан театр училищесы.
Казан медицина колледжы.
Атилла Расихның “Ике буйдак” романыннан өзек (“Тәҗрибә”).
Казан педагогия колледжы.
Фәнис Яруллинның “Сез иң гүзәл кеше икәнсез” шигыре.
Җырчы Миңгол Галиев иҗаты.
“Идел” журналы турында мәгълүмат.
Нур Әхмәдиевның “Авылдашым” шигыре.
Салисә Гәрәеваның “Токарь” шигыре.
Казан политехник колледжы.
Рашат Низаминың “Тимер чәчәк” хикәясеннән өзек.